| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**09.01.2023ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 01** |
|---|---|---|

Җәмәгать транспорты хезмәтләренең бердәм электрон исемле социаль юл билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 ноябрендәге 2281 номерлы карары белән расланган, Җәмәгать транспорты хезмәтләренең бердәм электрон исемле социаль юл билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составын, әлеге карардагы кушымтада бирелгәнчә, яңа редакциядә расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 ноябрендәге 2281 нче номерлы карары белән расланган, Җәмәгать транспорты хезмәтләренең бердәм электрон исемле социаль юл билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында» 3380 номерлы карарының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитетының
2023 елның 09 гыйнварындагы
01 номерлы карарына
кушымта

**Җәмәгать транспорты хезмәтләренең бердәм электрон исемле социаль юл билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составы**

| № т/б | Ф.И.Ат.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Старостин Александр Владимирович | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы - **Комиссия рәисе** |
| **Комиссия әгъзалары:** | | |
| 2 | Хәбибуллин Зөлфәт Флун улы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 3 | Ясельская Регина Романовна | «ЗМР төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкче урынбасары **комиссия секретаре** |
| 4 | Бауэр Анастасия Сергеевна | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм үсеш бүлеге башлыгы |
| 5 | Содомова Юлия Александровна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| 6 | Ламбина Татьяна Михайловна | «ЗМР финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкче урынбасары (килешү буенча) |
| 7 | Кадыйрова Светлана Викторовна | «Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы» МУ рәисе (килешү буенча) |